1. 1870 елгы шәһәр реформасы нигезендә төзелгән үзидарә органнары ничек дип аталган?

1) Думалар һәм управалар
2) дворян җыелышлары
3) департаментлар
4) магистратлар

2.Түбәндә санап кителгәннәрнең кайсысы Александр II үткәргән эчке сәясәт нәтиҗәсен чагылдыра?

1) бәйсез ачык судлар оешу
2) йолым түләүләре бетерелү
3) Дәүләт советы төзелү
4) земстволар эшчәнлеге тәмамлану

3. Дәүләт төзелешен үзгәртергә тырышып карау һәм Дәүләт советын оештыру, Царское Село лицеен ачу, университетларга автономия бирү кайсы патша идарә итү вакытында булган?

1) Павел I
2) Александр I
3) Николай I
4) Александр II

4. Императорлар Николай I һәм Александр II нең тышкы сәясәт үзенчәлекләрен чагыштырыгыз. Беренче баганага - охшашлыкларның, икенче баганага аерымлыкларның тәртип номерларын сайлап языгыз.

1) балкан халыкларының азатлык өчен көрәшен яклап чыгу
2) Урта Азия территорияләрен кушу һәм үзләштерү
3) Россия өчен уңайлы булган Кара диңгез бугазы режимы өчен көрәш
4) тышкы сәясәт изоляциясеннән чыгу өчен тарафдарлар эзләү

5. Петр I чорының күренекле архитектура һәйкәле булып тора:

1) Санкт-Петербургта Казан соборы
2) Санкт-Петербургта Михайловский сарае
3) Мәскәүдә Зур Кремль сарае
4) Санкт-Петербургта Петропавловский соборы

6. Тарихи вакыйгаларны хронологик тәртиптә урнаштырыгыз. Тарихи вакыйгалар билгеләнгән цифрларны таблицага дөрес тәртиптә языгыз.

1) Россияне континенталь блокадага кертү
2) Россиянең Җидееллык сугышта катнашуы
3) Европага «Бөек илчелек»
4) Россиянең Польшаны бүлүдә катнашуы

7. Императорлар Петр I һәм Николай I нең дәүләт белән идарә итү өлкәсендәге сәясәтләрен чагыштырыгыз. Беренче баганага - охшашлыкларның, икенче баганага аерымлыкларның тәртип номерларын сайлап языгыз.

1) ил белән идарә итүгә бәйле барлык мәсьәләләрнең император кулында туплануы
2) Россия империясендә Законнар җыелмасы язылу
3) коллегияләр эшчәнлеге
4) бюрократик аппарат саны арту

8. Солых килешүләренең атамалары һәм бу килешүләрнең шартлары арасында тәңгәллек табыгыз: икенче баганадан беренче баганадагы һәр элементка туры килүче элементны табыгыз.

| Солых килешүләренең атамалары | | Солых килешүләренең шартлары | |
|---|---|---|---|
| **А)** | Фридрихсгам солыхы | **1)** | Сахалин утравының көньяк өлеше Япониягә бирелә |
| **Б)** | Бухарест солыхы | **2)** | Выборгтан алып Ригага кадәр Балтыйк яр буйлары Россия составына керә |
| **В)** | Портсмут солыхы | **3)** | Бессарабия Россия составына керә |
| | | **4)** | Финляндия Россиягә кушыла |

Җаваплар рәтендә сайлап алынган саннарны тиешле хәрефләр астына языгыз.

9. Рус поэзиясенең Көмеш гасыр вәкилләре -

**1)** А.А. Фет, Ф.И. Тютчев

**2)** А.С. Пушкин, М.Ю. Лермонтов

**3)** Г.Р. Державин, А.Н. Радищев

**4)** А.А. Ахматова, А.А. Блок

10. Санап кителгән кайсы манифестка 1810 елда император кул куйган?

**1)** дошманнарны Россиядән куу һәм  Ватан сугышының тәмамлануы турында

**2)** Дәүләт советы оешу турында

**3)** Самодержавиянең ныклыгы турында

**4)** “Дәүләт тәртибен камилләштерү турында”

11. Александр I нең  патшалык итә башлау чорында либераль проектларны эшләүгә этәргеч ясаган сәбәпләрнең берсе булып тора...

1) славянофиллык идеяләре
2) рәсми халыкчанлык теориясе
3) мәгариф идеясе
4) община социализмы теориясе

11. Александр I нең  патшалык итә башлау чорында либераль проектларны эшләүгә этәргеч ясаган сәбәпләрнең берсе булып тора...

1) славянофиллык идеяләре
2) рәсми халыкчанлык теориясе
3) мәгариф идеясе
4) община социализмы теориясе

12. Россия империясе составына Финляндия кайчан кушылган?

1) 1720 елда
2) 1780 елда
3) 1800 елда
4) 1820 елда

13. Россия империясенең 1810 елда оешкан закон проектларын тикшерү буенча югары органы ничек дип аталган?

1) Югары  эш  алып бару комиссиясе
2) Дәүләт думасы
3) Дәүләт советы

**4)** Югары яшерен совет

Статистик таблица мәгълүматлары ярдәмендә түбәндә китерелгән фикерләрне, аларның баштагы җөмләләрен ахыргы җөмләләре белән туры китереп, тәмамлагыз.

*1874— 1880 елларда новобранецларны рус армиясенә кабул итү*

| Ел | Хәрби хезмәткә чакырылган (кеше) | Хәрби хезмәткә кабул ителгән (кеше) | Ополчениега кертелгән (кеше) |
|---|---|---|---|
| 1874 | 724 648 | 148 458 | 438 737 |
| 1877 | 689 825 | 211 510 | 477 373 |
| 1880 | 808 683 | 231 677 | 559 404 |

**Фикер башы**

**А)** 1877 елда хәрби хезмәткә кабул ителгәннщрнең саны

**Б)** Хәрби хезмәткә иң күп кабул ителгәннәрнең саны ... туры килә

**В)** 1877 елда ополчениега кабул ителгәннәрнең саны

**Фикерне тәмамлау өчен вариантлар**

**1)** 1874 елга караганда күбрәк булган

**2)** 1880 елга


**3)** 1874 елга карата үзгәрешсез калган

**4)** 1877 елга

**5)** 1874 елга караганда кимрәк булган

Җаваплар рәтендә сайлап алынган саннарны тиешле хәрефләр астына языгыз.

15. Схеманы карагыз.




Схемада кем җитәкчелегендәге баш күтәрүчеләрнең хәрәкәтләре һәм халык восстаниесе районы чагылдырылган?

**1)** И.И. Болотников

**2)** С.Т. Разин

**3)** К.А. Булганвин

**4)** Е.И. Пугачёв

16. Россиянең дәүләт башлыклары һәм алар идарә итү вакытында Россия составына кушылган территорияләр арасында тәңгәллек урнаштырыгыз: икенче баганадан беренче баганадагы һәр элементка туры килүче элементны табыгыз.

| **Россиянең дәүләт башлыклары** | **Россия составына кушылган территорияләр** |
| --- | --- |

**А)** Алексей Михайлович

**Б)** Пётр I

**В)** Екатерина II

**1)** Выборгтан Ригага кадәр Балтыйк яр буе


**2)** Урта һәм Түбән Идел буе

**3)** Сул як Украина

**4)** Төньяк Кара диңгез буе

Җаваплар рәтендә сайлап алынган саннарны тиешле хәрефләр астына языгыз.

17. Схеманы карагыз.




Схемада чагылдырылган вакыйгалар ничәнче елда булган?

**1)** 1700 елда

**2)** 1704 елда

**3)** 1708 елда

**4)** 1709 елда

18. Рәсемне карагыз.



Бу медаль кайсы вакыйгаларның хәтирәсе буларак чыгарылган?

**1)** Төньяк сугышның

**2)** Кырым  сугышының

**3)** 1877–1878 еллардагы рус-төрек сугышының

**4)** рус-япон сугышының

Җаваплар рәтендә сайлап алынган саннарны тиешле хәрефләр астына

языгыз.

19. Статистик таблица мәгълүматлары ярдәмендә түбәндә китерелгән фикерләрне, аларның баштагы җөмләләрен ахыргы җөмләләре белән туры китереп, тәмамлагыз.

*1804 һәм 1850 елларда Россиянең сәнәгать предприятиеләре*

| Ел | Киндер предприятиеләре | Эшчеләр | Шикәр предприятиеләре | Эшчеләр |
|---|---|---|---|---|
| 1804 | 285 | 23 711 | 7 | 108 |
| 1850 | 122 | 14 440 | 354 | 37 383 |

**ФИКЕР БАШЫ**

**А)** 1804 елдан алып 1850 кадәр киндер фабрикаларында эшләүче эшчеләрнең саны

**Б)** XIX гасырның беренче яртысында шикәр предприятиеләренең саны

**В)** 1804 елда уртача 20 дән ким эшче эшләде

**ФИКЕРНЕ ТӘМАМЛАУ ӨЧЕН ВАРИАНТЛАР**

**1)** ике тапкыр арткан

**2)** кимегән

**3)** якынча 50 тапкыр үскән

**4)** киндер предприятиеләрендә

**5)** шикәр предприятиеләрендә

Җаваплар рәтендә сайлап алынган саннарны тиешле хәрефләр астына языгыз.

20. Түбәндә санап кителгән фикерләрдән кайсылары славянофилларның карашларын чагылдыралар? Исемлектән ике фикерне сайлап алыгыз һәм аларга туры килгән цифрларны язып куегыз.

**1)** крестьян общинасы Россиянең мөстәкыйль үсешен тәэмин итә

**2)** крепостнойлык хокукының саклануы

**3)** Петр I реформаларына уңай бәя

4) Россия белән Европаның бер юл буенча үсүе

5) дәүләт реформалары ярдәмендә революция куркынычыннан котылу мөмкинлеге

21. Статистик таблица мәгълүматлары ярдәмендә түбәндә китерелгән фикерләрне, аларның баштагы җөмләләрен ахыргы җөмләләре белән туры китереп, тәмамлагыз.

*Кырым сугышы вакытында Россиянең дәүләт бюджеты*

| Ел | 1853 | 1854 | 1855 |
|---|---|---|---|
| Керем (мең сум) | 227 471 | 242 380 | 261 504 |
| Чыгым (мең сум) | 336 298 | 389 312 | 544 139 |

**ФИКЕР БАШЫ**

**А)** Кырым сугышы вакытында ... тизрәк үскән

**Б)** Дәүләт бюджетының чыгымы керемгә караганда якынча ике тапкыр арткан

**В)** Чыгымның керемгә караганда артуы минималь дәрәҗәдә

**ФИКЕРНЕ ТӘМАМЛАУ ӨЧЕН ВАРИАНТЛАР**

**1)** 1853 елда

**2)** 1854 елда

**3)** дәүләт бюджетының чыгымы

**4)** 1855 елда

**5)** дәүләт бюджетының кереме

Җаваплар рәтендә сайлап алынган саннарны тиешле хәрефләр астына языгыз.

22. XVIII гасырда сарай переворотлары эпохасының бер сәбәбе булып нәрсә торган?

**1)** Петра I нең тәхет варислыгы турында законы

**2)** Нарышкин белән Милославский арасында хакимлек өчен көрәш

**3)** Э. Биронның сарайда йогынтысы көчәю

**4)** бояр төркемнәре арасында сарайга йогынты өчен барган көрәшкә укчыларның катышуы

23. Укчылар гаскәре һәм Петр I нең регуляр армиясенең оешу үзенчәлекләрен чагыштырыгыз. Беренче баганага - охшашлыкларның, икенче баганага аерымлыкларның тәртип номерларын сайлап языгыз.

**1)** ату коралларын куллану

**2)** хәрби хезмәтне кәсепчелек һәм вак сәүдә эше белән берләштерү

**3)** полкларга бүленү

**4)** хәрби устав төзү

23. Тарихи вакыйгаларны хронологик тәртиптә урнаштырыгыз. Тарихи вакыйгалар билгеләнгән саннарны таблицага дөрес тәртиптә языгыз.

**1)** гомуми хәрби йөкләмә кертү

**2)** крепостнойлык хокукын бетерү

**3)** самодержавиенең ныклыгы турында манифест чыгару

**4)** земство реформасы

24. Статистик таблица мәгълүматлары ярдәмендә түбәндә китерелгән фикерләрне, аларның баштагы җөмләләрен ахыргы җөмләләре белән туры китереп, тәмамлагыз.

*Рус портларының еллык әйләнешләре*

| Ел | Санкт-Петербург | Архангельский | Әстерхан |
|---|---|---|---|
| 1719 | 1976 мең сум | 2942 мең сум | 961 мең сум |
| 1726 | 3953 мең сум | 245 мең сум | 988 мең сум |

**ФИКЕР БАШЫ**

**А)** 1726 елда порт аша тормышка ашырыла торган сәүдә күләме 10 тапкыр кимегән

**Б)** 1726 елга илнең төп диңгез капкасы булган

**В)** Таблицада күрсәтелгән өч портның гомуми еллык әйләнеше зуррак

**ФИКЕРНЕ ТӘМАМЛАУ ӨЧЕН ВАРИАНТЛАР**

**1)** 1726 елда

**2)** 1719 елда

**3)** Астрахань

**4)** Архангельск

**5)** Санкт-Петербург

Җаваплар рәтендә сайлап алынган саннарны тиешле хәрефләр астына языгыз.

25. Хәбәрдән өзек укыгыз һәм сүзнең нинди вакыйга турында баруын билгеләгез.
“Безнең яктан кавалериянең уң ягы белән генерал-лейтенант Баур...сул як белән кенәз Меншиков галиҗәнәпләре җитәкчелек итте, аның анда булуы бик мөһим иде. Ә корпус баталиясе белән патша галиҗәнәпләре үзе җитәкчелек итте... аның янында генерал-фельтмаршал Шереметев әфәнде, шулай ук инфатериядән генераллар кенәз Репнин һәм Аларт...Артиллерия белән артиллериядән генерал-порутчик Брюс идарә итте...Безнең гаскәр дошманга  таба китте һәм төш алдыннан сәгать тугызларда ике яктан да һөҗүм һәм көчле атышу башланды, безнекеләр һөҗүмдә шундый батырлык күрсәттеләр ки, аз югалтулар белән, ярты сәгатьлек сугышта дошман армиясенең, кавалериясен дә, инфантериясен дә кире кактылар, швед инфантериясе бүтән бер тапкыр да туктамады. Шулай итеп, алланың рәхмәте белән, моңа кадәр аз ишетелгән һәм аз күрелгән җиңү яуланды».

**1)** Нарва камалышы

**2)** Кунерсдорф янында сугыш

**3)** Азов камалышы

**4)** Полтава сугышы

26. Тарихи вакыйгаларны хронологик тәртиптә урнаштырыгыз. Тарихи вакыйгалар билгеләнгән саннарны таблицага дөрес тәртиптә языгыз.

**1)** Е.И. Пугачёв җитәкчелегендә восстание башлану

**2)** дворяннарга жалованный грамота бастырып чыгару

**3)** Уложенный комиссия чакырып алу

**4)** Екатерина II нең губерна реформасы

27. Алда санап кителгән реформаларның кайсылары 1860-1870 еллардагы Бөек реформалар чорында тормышка ашырылган? Исемлектән ике реформаны сайлап алыгыз һәм аларга туры килгән цифрларны язып куегыз.

**1)** Губерна реформасы

**2)** Министрлык реформасы

**3)** Чиркәү реформасы

**4)** Земство реформасы

**5)** Суд реформасы

28. Тарихи вакыйгаларны хронологик тәртиптә урнаштырыгыз. Тарихи вакыйгалар билгеләнгән саннарны таблицага дөрес тәртиптә языгыз.

**1)** Россияне империя дип игълан итү

**2)** тәхетне ир линиясе буенча гына мирас итеп алып булу турында боерык чыгару

**3)** дворяннарның иреге турында манифест чыгару

**4)** Санкт-Петербургка нигез салыну

29. 1720 һәм 1740 еллардагы Россия дворянлыгы турындагы нигезләмәләрне чагыштырыгыз. Таблицаның беренче баганасына охшаш якларны, икенчесенә – аермалыкларны сайлап алып языгыз.

1) дәүләт хезмәтенең мәҗбүрилеге
2) хезмәт итүне Ранглар турында табельгә нигезләнеп үтү
3) дворян  утарларын варислар арасында бүлү хокукы
4) хезмәт итүне 25 ел белән чикләү

30. Тарихчы язмасыннан өзек укыгыз һәм кайсы императрица турында сүз барганын ачыклагыз.
“1762 елның июнь перевороты аны самодержавияле рус патшабикәсе итте. Язмаларында ярсыган аңының төрле кызыксынулары да, мавыгулары да чагылыш тапты. Тумышы буенча алман, яраткан теле һәм тәрбиясе  буенча француженка, ул XVIII гасыр рус язучыларының әсәрләрендә күренекле урын алды. Ул французча, хәтта русча да күп язды, дөрес, хаталар белән... Ул көнне ничек бер бит тә сызгаламыйча үткәреп булуын аңламавын әйтә иде...  Аның Вольтер һәм чит ил бароны Грим белән  язышуы – тулы томнар булып тора.”

1) Елизавета Петровна
2) Анна Иоанновна
3) Екатерина II
4) Екатерина I

31. Россиядә затлы нәселдән булган кызлар өчен Смольный институты кайчан ачылган?

1) XVIII гасырның икенче яртысында
2) XIX гасыр башында
3) XIX  60 нчы елларында
4) XX гасыр башында

32. Петр I һәм Николай I нең эчке сәясәт үзенчәлекләрен чагыштырыгыз. Беренче баганага охшаш якларны, икенчесенә – аермалыкларны сайлап алып языгыз.

1) “Рәсми халыкчанлык теориясе”н пропагандалау
2) ил эчендә баш күтәрүләрне басу
3) ил белән министрлыклар ярдәмендә идарә итү
4) бюрократия аппаратының үсеше

33. Рәсми халыкчанлык теориясе кайчан барлыкка килгән?

1) 1790 елда
2) 1810 елда
3) 1830 елда
4) 1860 елда

34. Кайсы сугыш барышында Синоп янындагы диңгез бәрелеше булган?

1) Төньяк сугышында
2) Җидееллык сугышында
3) Кырым сугышында
4) Рус-япон сугышында

35. С.Т. Разин һәм Е.И. Пугачев җитәкчелегендәге халык восстаниеләренең үзенчәлекләрен чагыштырыгыз. Беренче баганага охшаш якларны, икенчесенә – аермалыкларны сайлап алып языгыз.

1) восстаниедә тау заводы эшчеләренең канашуы
2) восстаниенең илнең читендә башлануы
3) восстаниедә катнашучыларның сарай учреждениеләрен, чиннарын һәм этикетларын кабатлау

**4)** крестьян массаларының стихияле катнашуы

36. “1864 елда суд реформасы барышында артык әһәмияте булмаган эшләрне тикшерү һәм вак гражданнар шикаятьләрен карау өчен барлыкка килгән сайлау суды” аңлатмасына туры килә торган терминны языгыз.

37. Зиннәтлелек һәм монументальлек үзенчәлекләре фасадларның хикмәтле линияләре һәм күпләп әвәләп ясалган бизәкләр белән ярашкан XVIII гасыр архитектура стилен күрсәтегез.

**1)** модернизм

**2)** барокко

**3)** классицизм

**4)** конструктивизм

38. “XIX гасыр башында барлыкка килгән, бер генә җитәкчесе булган һәм турыдан-туры императорга гына буйсынган үзәк идарә итү органнары” аңлатмасына туры килгән терминны языгыз.

39. Россиянең рус-япон сугышында һәм Беренче бөтендөнья сугышында катнашу үзенчәлекләрен чагыштырыгыз. Беренче баганага охшаш якларны, икенчесенә – аермалыкларны сайлап алып языгыз.


**1)** сугышта катнашу илдә революцион ситуация тудыра

**2)** Россия сугышта коалиция составында катнаша

**3)** сугыш хәрәкәтләре Россия империясенең Европа территориясендә бара

**4)** сугышның бетүен раслый торган солых килешүенең шарты булып Россиянең территорияләрен югалту тора

40. Схеманы карагыз.




1812 елда Россия империясе составына кергән территория схемада нинди цифр белән билгеләнгән?

**1)** I

2) II

3) III

4) IV

41. Санап кителгән чараларның кайсылары дәүләт хакимияте органнары реформасы һәм император Александр I идарәсе нәтиҗәсендә тормышка ашырылган? Исемлектән ике чараны сайлап алыгыз һәм аларга туры килгән цифрларны язып куегыз.

1) Дәүләт думасының чакырылышы

2) министрлыклар барлыкка килү

3) Дәүләт советы оешу

4) Император галиҗәнәпләре шәхси канцеляриясенең III бүлеген ачу

5) Сенатны бетерү

42. А.Г. Венецианов, И.Е. Репин кемнәр булганнар?

1) рәссамнар

2) скульпторлар

3) архитекторлар

4) драматик артистлар

43. Александр I вакытында үткәрелгән халык мәгарифе системасы реформасы барышында...

1) университетларга киң автономия бирелгән

2) студент оешмаларының эшчәнлеге тыелган

3) хатын-кызлар өчен беренче уку оешмалары ачылган

4) барлык катлау кешеләре өчен цифирлы мәктәпләр барлыкка килгән

44. Схеманы карагыз.




Схемада нинди вакыйгалар чагылдырылган?

**1)** Төньяк сугышы

**2)** Рус армиясенең 1813—1814 елларда чит илгә походы

**3)** 1877—1878 елларда рус-төрек сугышы

**4)** рус-япон сугышы

46. Рәсемне карагыз һәм  биремне үтәгез.



Әлеге картина сынлы сәнгатьнең кайсы юнәлешенә туры килә?


**1)** романтизм

**2)** академизм

**3)** авангардизм

**4)** критик реализм

47. Рәсемне карагыз һәм сорауга җавап бирегез.



Әлеге рәсемдә нинди вакыйга тасвирланган?

**1)** Кырым сугышы

**2)** Александр II нең народниклар тарафыннан үтерелүе

**3)** декабристлар восстаниесе

**4)** С.Т. Разин җитәкчелегендәге восстание

48. Сурәтне карагыз һәм биремне үтәгез.



Әлеге архитектура һәйкәленең архитектура стилен атагыз.

**1)** барокко

**2)** чатыр стиле

**3)** классицизм

**4)** модерн

49. Тарихи вакыйгаларны хронологик тәртиптә урнаштырыгыз. Тарихи вакыйгалар билгеләнгән саннарны таблицага дөрес тәртиптә языгыз.

**1)** Төньяк сугышы башлану

**2)** Казан ханлыгының Россия империясенә кушылуы

**3)** А.С. Суворов җитәкчелегендәге рус гаскәрләренең Альпны кичүе

**4)** Кырымның Россия империясенә кушылуы

50. Тарихи вакыйгаларны хронологик тәртиптә урнаштырыгыз. Тарихи вакыйгалар билгеләнгән саннарны таблицага дөрес тәртиптә языгыз.

**1)** Россияне империя дип игълан итү

**2)** Дворяннар иреге турында Манифест кабул итү

**3)** А.С.Суворов җитәкчелегендәге рус гаскәрләренең Измаил крепостен алуы

**4)** Санкт-Петербургка нигез салу

51. Тарихи вакыйгаларны хронологик тәртиптә урнаштырыгыз. Тарихи вакыйгалар билгеләнгән саннарны таблицага дөрес тәртиптә языгыз.

**1)** Төньяк сугышы

**2)** Смоленский сугышы

**3)** Ливон сугышы

**4)** Җидееллык сугыш

52. Санап кителгән төшенчәләрнең кайсылары XIX гасырның 60-70 елларында Россиядә Бөек реформалар вакытында барлыкка килгән? Исемлектән ике төшенчне сайлап алыгыз һәм аларга туры килгән цифрларны язып куегыз.

**1)** губернияләр

**2)** министерстволар

**3)** ирекле игенчеләр

**4)** катламсыз суд

**5)** җәмәгать арадашчылары

53. Түбәндә санап кителгән дәүләт эшлеклеләренең кайсылары XIX гасырда Россиянең тышкы сәясәт юнәлешләрен билгеләгән? Исемлектән ике эшлеклене сайлап алыгыз һәм аларга туры килгән цифрларны язып куегыз.

1) С.С. Уваров
2) А.М. Горчаков
3) П.Д. Киселёв
4) К.В. Нессельроде
5) М.М. Сперанский

54. Түбәндә санап кителгән вакыйгаларның кайсылары Беренче Россия революциясе вакытында булган? Исемлектән ике вакыйгыны сайлап алыгыз һәм аларга туры килгән цифрларны язып куегыз.

1) генерал Л.Г. Корнилов чыгышы
2) Октябрь сәяси стачкасы
3) I Бөтенроссия Советлар съезды
4) Канлы якшәмбе
5) Солых турында декрет кабул итү

55. Түбәндә санап кителгән дәүләт эшлеклеләренең кайсылары император Александр I вакытындагы Яшерен комитет составына кергән? Исемлектән ике эшлеклене сайлап алыгыз һәм аларга туры килгән цифрларны язып куегыз.

1) В.П. Кочубей
2) А.А. Чарторыйский
3) Е.Ф. Канкрин
4) М.М. Сперанский
5) А.А. Аракчеев

56. Түбәндә санап кителгән дәүләт органнарының кайсылары 1907 – 1917 елларда Россия империясендә эшләгән? Исемлектән ике органны сайлап алыгыз һәм аларга

туры килгән цифрларны язып куегыз.

1) Яшерен комитет
2) Югары яшерен совет
3) Министрлар советы
4) Учредительное собрание
5) Дәүләт думасы

57. Түбәндә санап кителгән гаскәр башлыкларының кайсылары 1877—1878 еллардагы рус-төрек сугышында катнашкан? Исемлектән ике гаскәр башлыгын сайлап алыгыз һәм аларга туры килгән цифрларны язып куегыз.

1) П.И. Багратион
2) М.Б. Барклай де Толли
3) М.Д. Скобелев
4) И.И. Дибич
5) И.В. Гурко

58. Түбәндә санап кителгән тарихи эшлеклеләрнең кайсылары Кырым сугышы вакытында Севастополь оборонасында катнашкан? Исемлектән ике эшлеклене сайлап алыгыз һәм аларга туры килгән цифрларны язып куегыз.

1) В.А. Корнилов
2) П.С. Нахимов
3) А.П. Ермолов
4) Д.В. Давыдов
5) М.Д. Скобелев

59. Түбәндә санап кителгән положениеләрнең кайсылары П.А. Столыпинның аграр реформасын чагылдыра? Исемлектән ике положениене сайлап алыгыз һәм аларга туры килгән цифрларны язып куегыз.

1) алпавыт җирбиләүчелеген бетерү
2) отруб һәм хутор җирбиләүчелеге үсеше
3) крестьян хуҗалыкларын коллективлаштыру
4) җиргә шәхси милекчелекне бетерү
5) крестьян общинасының җимерелүе

60. Түбәндә санап кителгән дәүләт эшлеклеләренең кайсылары Александр I идарә итү чорында дәүләт төзелешен үзгәртү турында проектны эшләүгә катнашалар? Исемлектән ике эшлеклене сайлап алыгыз һәм аларга туры килгән цифрларны язып куегыз.

1) Н.Н. Новосильцев
2) А.Х. Бенкендорф
3) Д.А. Милютин
4) М.М. Сперанский
5) П.Д. Киселёв

61. Түбәндә санап кителгән бәрелешләрнең кайсылары 1812 елгы Ватан сугышы вакытында булган? Исемлектән ике бәрелешне сайлап алыгыз һәм аларга туры килгән цифрларны язып куегыз.

1) Полтава сугышы
2) Плевна штурмы
3) Аустерлиц янындагы бәрелеш
4) Березина елгасы янындагы сугыш
5) Смоленск сугышы

62. Түбәндә санап кителгән вакыйгаларның  кайсылары Петр I идарә итү чорына туры килә? Исемлектән ике вакыйганы сайлап алыгыз һәм аларга туры килгән цифрларны язып куегыз.

1) Беренче Земский соборны чакырып алу
2) Изге Синод төзү
3) крепостной хокукны бетерү
4) Беренче Дәүләт Думасын чакырып алу
5) Рекрут йөкләмәсен кертү

63. Түбәндә санап кителгәннәрнең  кайсылары Россиянең XX гасыр башында икътисади яктан үсешен характерлый? Исемлектән ике җавапны сайлап алыгыз һәм аларга туры килгән цифрларны язып куегыз.

1) монополияләр барлыкка килү
2) беренче мануфактуралар барлыкка килү
3) чит ил капиталын җәлеп итү
4) сәнәгать борылышлары башлану
5) беренче тимер юллар төзү

64. Түбәндә санап кителгән хакимият органнарының  кайсылары XIX гасырның беренче чирегендә төзелгән? Исемлектән ике җавапны сайлап алыгыз һәм аларга туры килгән цифрларны язып куегыз.

1) министерстволар
2) Изге Синод
3) Дәүләт советы
4) Дәүләт думасы
5) Хакимлек итүче сенат

65. Түбәндә санап кителгән оешмаларның  кайсылары народниклар тарафыннан төзелгән ? Исемлектән ике оешманы сайлап алыгыз һәм аларга туры килгән цифрларны язып куегыз.

**1)** «Земля и воля»

**2)** Төньяк җәмгыяте

**3)** “Эшчеләр сыйныфын азат итү өчен көрәш союзы”

**4)** Коткару союзы

**5)** «Чёрный передел»

66. Түбәндә санап кителгән дәүләт эшлеклеләренең  кайсылары XIX гасырда Россия империясенең финанслар министры постында торган? Исемлектән ике эшлеклене сайлап алыгыз һәм аларга туры килгән цифрларны язып куегыз.

**1)** К.П. Победоносцев

**2)** С.Ю. Витте

**3)** Д.А. Толстой

**4)** А.А. Аракчеев

**5)** Е.Ф. Канкрин

67. Түбәндә санап кителгән территорияләрнең  кайсылары XIX гасырда Россия составына кергән? Исемлектән ике эшлеклене сайлап алыгыз һәм аларга туры килгән цифрларны язып куегыз.

**1)** Финляндия

**2)** Лифляндия һәм Эстляндия

**3)** Төньяк Себер

**4)** Урта һәм Түбән Идел буе

**5)** Польша

68. Түбәндә санап кителгән сугышларның  кайсылары XVIII гасырда булган? Исемлектән ике сугышны сайлап алыгыз һәм аларга туры килгән цифрларны язып куегыз.

**1)** Полтава сугышы

**2)** Аустерлиц сугышы

**3)** Фридланд янындагы сугыш

**4)** Бородино сугышы

**5)** Гренгам утравы янындагы сугыш

69. Түбәндә санап кителгән вакыйгаларның  кайсылары XX гасырның беренче унъеллыгында булган? Исемлектән ике вакыйганы сайлап алыгыз һәм аларга туры килгән цифрларны язып куегыз.

**1)** Рус-япон сугышы

**2)** Николай II нең тәхеткә менүе

**3)** I Дәүләт думасына сайлаулар

**4)** Россиянең Беренче дөнья сугышына керүе

**5)** Җир турында Декрет кабул итү

70. Статистик таблица мәгълүматлары ярдәмендә түбәндә китерелгән фикерләрне, аларның баштагы җөмләләрен ахыргы җөмләләре белән туры китереп, тәмамлагыз.

*1861 елгы реформадан соң алпавыт хуҗалыгы*

| Җирлек | Эш буенча түләү системасының өстенлек итүе | Катнаш түләү системасының өстенлек итүе | Капиталистик системаның өстенлек итүе |
|---|---|---|---|
| Кара туфраклы губернияләр | 50% | 12% | 38% |
| Кара туфраксыз губернияләр | 28% | 20% | 52% |

**<u>ФИКЕР БАШЫ</u>**

**А)** Хуҗалык алып баруда капиталистик система өстенлек иткән

**Б)** Кара туфраксыз полосада хуҗалык итүнең катнаш түләү системасы булган губернияләр саны

**В)** Кара туфраклы полосада хуҗалык итүнең эш буенча түләү системасы булган губернияләр саны

**<u>ФИКЕРНЕ ТӘМАМЛАУ ӨЧЕН ВАРИАНТЛАР</u>**

**1)** кара туфраклы губернияләрдә

**2)** гомуми саннан яртысын тәшкил иткән

**3)** кара туфраксыз губернияләрдә

**4)** гомуми саннан биштән бер өлешен тәшкил иткән

**5)** гомуми саннан бары тик уннан бер өлешен тәшкил иткән

Җаваплар рәтендә сайлап алынган саннарны тиешле хәрефләр астына языгыз.

71. Статистик таблица мәгълүматлары ярдәмендә түбәндә китерелгән фикерләрне, аларның баштагы җөмләләрен ахыргы җөмләләре белән туры китереп, тәмамлагыз.
*XVIII гасырда үткәрелгән ревизия күрсәткечләре (салым түли торган халык санын алу)*

| ревизиянең №№ | Ел | Халык саны, млн кеше |
|---|---|---|
| 1 | 1722 | 14 |
| 2 | 1742 | 16 |
| 3 | 1762 | 19 |
| 4 | 1782 | 28 |
| 5 | 1796 | 36 |

**ФИКЕР БАШЫ**

**А)** Салым түли торган халыкның уртача иң күп еллык артуы ... ревизияләр үткәрү арасына туры килә

**Б)** Салым түли торган халыкның уртача иң аз еллык артуы ... ревизияләр үткәрү арасына туры килә

**В)** XVIII гасырда Россиядә ревизияләр ... үткәрелгән

**ФИКЕРНЕ ТӘМАМЛАУ ӨЧЕН ВАРИАНТЛАР**

**1)** 1722 һәм 1742 елларда

**2)** 1762 һәм 1782 елларда

**3)** 1782 һәм1796 елларда

**4)** һәрвакыт тигез вакыт аралыгында

**5)** һәрвакыт тигез вакыт аралыгында түгел

Җаваплар рәтендә сайлап алынган саннарны тиешле хәрефләр астына языгыз.

72. Статистик таблица мәгълүматлары ярдәмендә түбәндә китерелгән фикерләрне, аларның баштагы җөмләләрен ахыргы җөмләләре белән туры китереп, тәмамлагыз.
*XIX гасырда кайбер илләрдә шәһәр халкы проценты (саны)*

| Ил | 1800 г. | 1850 г. | 1890 г. |
|---|---|---|---|
| Россия | 8,5 | 7,2 | 12,5 |
| Бөекбритания | 21,3 | 39,5 | 72,1 |
| АКШ | 3,8 | 12 | 37,7 |

**ФИКЕР БАШЫ**

**А)** 1850 елда Россиядә шәһәр халкы проценты (саны)

**Б)** 1850 елда Бөекбританиядә шәһәр халкы проценты (саны)

**В)** Таблица күрсәткечен генә файдаланып

**ФИКЕРНЕ ТӘМАМЛАУ ӨЧЕН ВАРИАНТЛАР**

**1)** Илдә гомуми халык саны турында нәтиҗә ясап булган

**2)** Илдә гомуми халык саны турында нәтиҗә ясап булмый

**3)** 50% арта

**4)** АКШтагы шәһәр халкы санынннан якынча 2 тапкырга күбрәк

**5)** 1800 елга караганда азрак

Җаваплар рәтендә сайлап алынган саннарны тиешле хәрефләр астына языгыз.

73. Статистик таблица мәгълүматлары ярдәмендә түбәндә китерелгән фикерләрне, аларның баштагы җөмләләрен ахыргы җөмләләре белән туры китереп, тәмамлагыз.
*Екатерина II вакытында дәүләт чыгымнары (% ларда)*

| Еллар | Сарайга | Армиягә | Флотка | Эчке идарәгә |
|---|---|---|---|---|
| 1781 | 11,5% | 26,3% | 8% | 54,2% |
| 1796 | 11,8% | 28,4% | 9% | 50,8% |

**ФИКЕР БАШЫ**

**А)** Таблицада күрсәтелгән елларда Екатерина II нең дәүләт чыгымнарының яртыдан күбесе

**Б)** Таблицада күрсәтелгән елларда Екатерина II нең Сарайны тотуга киткән чыгымнары

**В)** 1781 ел белән чагыштырганда, патшабикнең соңгы ел идарә итү чорында эчке идарәгә тоткан чыгымнары

**ФИКЕРНЕ ТӘМАМЛАУ ӨЧЕН ВАРИАНТЛАР**

**1)** кимегән

**2)** үскән

**3)** эчке идарәгә тоткан чыгымнарга караганда күбрәк булган

**4)** армиягә тотылган

**5)** флотка тотылган

Җаваплар рәтендә сайлап алынган саннарны тиешле хәрефләр астына языгыз.

74. Статистик таблица мәгълүматлары ярдәмендә түбәндә китерелгән фикерләрне, аларның баштагы җөмләләрен ахыргы җөмләләре белән туры китереп, тәмамлагыз.

*1867— 1880 елларда Россиянең кара туфраклы үзәгендә барщина крестьяннарының оброкка күчү динамикасы (крестьяннарының гомуми санына карата % ларда)*

| Губернияләр | Оброкка күчә | | 1881 елга барщина крестьяннары кала |
|---|---|---|---|
| | 1867— 1869 елларда | 1870— 1880 елларда | |
| Воронеж | 9,5 | 7,7 | 12,1 |
| Курск | 11,4 | 20,9 | 20,7 |
| Орлов | 28,0 | 29,6 | 8,0 |
| Тамбов | 12,9 | 10,8 | 14,0 |

**ФИКЕР БАШЫ**

**А)** 1867— 1880 елларда ... крестьяннар оброкка аеруча интенсив күчкәннәр

**Б)** 1881 елга барщина крестьяннарының проценты ... аеруча күп булган

**В)** Воронеж һәм Тамбов губернияләрендә крестьяннар ... аеруча оброкка интенсив күчкәннәр

**ФИКЕРНЕ ТӘМАМЛАУ ӨЧЕН ВАРИАНТЛАР**

**1)** Воронеж губерниясендә

**2)** 1867— 1869 елларда

**3)** Курск губерниясендә

**4)** Орлов губерниясендә

**5)** 1870— 1880 елларда

Җаваплар рәтендә сайлап алынган саннарны тиешле хәрефләр астына языгыз.

75. Статистик таблица мәгълүматлары ярдәмендә түбәндә китерелгән фикерләрне, аларның баштагы җөмләләрен ахыргы җөмләләре белән туры китереп, тәмамлагыз.

*Төп тармакларның продукция үсеше (млн. потларда)*

| Еллар | Нефть | Чуен | корыч | Ташкүмер |
|---|---|---|---|---|
| 1861 | 0,2 | 19,5 | 12,4 | 23,5 |
| 1881 | 40,4 | 28,7 | 21,2 | 213,3 |

**ФИКЕР БАШЫ**

**А)** 1861 елда нефть табу күләме

**Б)** 1861 елда корыч эретү күләме

**В)** 1861— 1881 елларда ташкүмер чыгару күләме

**ФИКЕРНЕ ТӘМАМЛАУ ӨЧЕН ВАРИАНТЛАР**

**1)** 1881 ел дәрәҗәсенең 1% тан кимрәк

**2)** якынча 9 тапкыр арткан

**3)** 1881 ел күләменең 60% тәшкил иткән

**4)** 90% ка арткан

**5)** 1881 ел күләменең 90% тәшкил иткән

Җаваплар рәтендә сайлап алынган саннарны тиешле хәрефләр астына языгыз.

76. Статистик таблица мәгълүматлары ярдәмендә түбәндә китерелгән фикерләрне, аларның баштагы җөмләләрен ахыргы җөмләләре белән туры китереп, тәмамлагыз.

*XIX гасырда Россиядә эшчеләр саны*

| Сәнәгать предприятияләрендә эшчеләр саны | 1804 ел | 1825 ел | 1860 ел |
|---|---|---|---|
| ялланган | 45,6 мең | 114,5 мең | 493,7 мең |
| посессион | 30 мең | 29 мең | 11 мең |

**ФИКЕР БАШЫ**

**А)** 1825 елда сәнәгать предприятияләрендә эшчеләр саны

**Б)** 1860 елда ялланган эшчеләр саны

**В)** 1860 елда посессион эшчеләр саны

**ФИКЕРНЕ ТӘМАМЛАУ ӨЧЕН ВАРИАНТЛАР**

**1)** ярты миллионнан артык булган

**2)** XIX гасыр башы белән чагыштырганда 10 тапкырга арткан

**3)** XIX гасыр башы белән чагыштырганда 2/3 кә кимегән

**4)** 200 меңнән кимрәк булган

**5)** үзгәрешсез калган

Җаваплар рәтендә сайлап алынган саннарны тиешле хәрефләр астына языгыз.

77. Статистик таблица мәгълүматлары ярдәмендә түбәндә китерелгән фикерләрне,

аларның баштагы җөмләләрен ахыргы җөмләләре белән туры китереп, тәмамлагыз.

*Россиядән  кайбер продуктларны чит илләргә чыгару (сумнарда)*

| Еллар | Сәнәгать продуктлары | Терлекчелек продуктлары | Игенчелек продуктлары | Индустрия продуктлары | Экспортка китә торган продуктларның гомуми суммасы |
|---|---|---|---|---|---|
| 1760 нчы еллар | 2 916 081 | 945 282 | 7 892 000 | 2 133 137 | 13 886 500 |
| 1790 нчы еллар | 10 029 679 | 5 193 233 | 18 711 496 | 5 708 592 | 39 643 000 |

**ФИКЕР БАШЫ**

**А)** 1790 елда Россия экспортында игенчелек продуктларының өлеше

**Б)** Россиядән экспортка китә торган сәнәгать продуктларының бәясе

**В)** Чит илгә чыгарыла торган ... гомуми бәясе зур темплар белән үскән

**ФИКЕРНЕ ТӘМАМЛАУ ӨЧЕН ВАРИАНТЛАР**

**1)** 2 тапкыр арткан

**2)** терлекчелек продуктларының

**3)** кимегән

**4)** индустрия продуктларының

**5)** 3 тапкыр арткан

Җаваплар рәтендә сайлап алынган саннарны тиешле хәрефләр астына языгыз.

78. Статистик таблица мәгълүматлары ярдәмендә түбәндә китерелгән фикерләрне, аларның баштагы җөмләләрен ахыргы җөмләләре белән туры китереп, тәмамлагыз.

*1825 —  1850 елларда Россиядә сәнәгать предприятияләренең саны*

| Ел | Кәгазь җитештерү | Киндер туку | Тимер һәм чуен |
|---|---|---|---|

| | | | |
|---|---|---|---|
| | фабрикалары | фабрикалары | заводлары |
| 1825 | 484 | 196 | 170 |
| 1850 | 480 | 122 | 416 |

**ФИКЕР БАШЫ**

**А)** XIX гасырның беренче чирегендә ... үзгәрмәгән диярлек

**Б)** Тимер юллар төзү сәбәпле 1825 елдан алып 1850 елга кадәр ... үскән

**В)** 1825 елдан алып 1850 елга кадәр киндер сугу фабрикаларының саны

**ФИКЕРНЕ ТӘМАМЛАУ ӨЧЕН ВАРИАНТЛАР**

**1)** үскән

**2)** кәгазь җитештерү фабрикаларының саны

**3)** кимегән

**4)** тимер һәм чуен заводларының саны

**5)** киндер туку Фабрикаларының саны

Җаваплар рәтендә сайлап алынган саннарны тиешле хәрефләр астына языгыз.

79. Кайсы тышкы сәяси союз Александр III катнашында үзенең эшчәнлеген башлап җибәрде?

**1)** Изге Союз

**2)** Өч император союзы

**3)** Антанта

**4)** Өчле Союз

80. Россиядә Эшче депутатлар советы барлыкка килү кайсы вакыйга белән бәйле?

**1)** Беренче Россия революциясе

**2)** Россиянең Беренче бөтендөнья сугышына керүе

**3)** Февраль революцисе

**4)** Гражданнар сугышының башлануы

81. Түбәндә санап кителгән төшенчәләрнең кайсысы турыдан-туры П.А. Столыпинның аграр реформасы белән бәйле?

**1)** күчереп утырту сәясәте

**2)** устав грамоталары

**3)** вакытлыча бурычлы крестьяннар

**4)** җирне национализацияләү

82. XX гасыр башында большевиклар дип атаганнар ...

**1)** Россия социал-демократик эшчеләр партиясендәге бер фракция вәкилләрен

**2)** Дәүләт думасындагы парламент күпчелеген

**3)** народниклык хәркәтендә катнашучыларны

**4)** иҗтимагый хәрәкәттәге либераль каталау вәкилләрен

83. Түбәндә санап кителгән оешмаларның кайсысы 1883 елда барлыкка килгән?

**1)** «Эшчеләрнең көньяк Россия союзы»

**2)** «Рус эшчеләренең төньяк союзы»

**3)** «Эшчеләр сыйныфын азат итү өчен көрәш союзы»

**4)** «Хезмәтне азат итү»

84. Тарихчы язмасынннан өзекне укыгыз һәм кайсы патшабикә турында сүз

барганын ачыклагыз.
“Кайчан да булса Россия тәхетендә утырганнарның берсенең дә аның кадәр патша таҗына аз хокуклы булганы юк иде. Ләкин аның идарә итүе Россия тарихында иң яхшы вакыт булды. Бу күренеш бер үк вакытта уникаль, XVIII гасыр Россиясе өчен үзенчәлекле иде. Нәкъ менә ул Петр I нең күп эшләрен ахырына җиткерде һәм дәүләт белән идарә итүнең яңа принципларын тапты”.

1) Екатерина Беренче
2) Екатерина Икенче
3) Елизавета Петровна
4) Патшабикә Софья

85. Түбәндә санап кителгән кешеләрнең кайсысы XX гасыр башында Парижда рус театры сезонын оештырган?

1) Д.Д. Шостакович
2) С.П. Дягилев
3) И.Н. Крамской
4) А.М. Горький

86. Түбәндә санап кителгән шәхесләрнең кайсысы Россиядә ачык театр оештырган?

1) А.Д. Кантемир
2) М.В. Ломоносов
3) Ф.Г. Волков
4) А.П. Сумароков

87. Түбәндә санап кителгәннәрнең кайсысы 1905 елның 17 октябрь манифестын басып чыгару нәтиҗәсе булып тора?

1) патшаның закон чыгару көченең чикләнүе

2) алпавыт җирләрен национализацияләү

3) идарә итүдә республика формасын кертү

4) эсерлар партиясенең хакимият белән көршүне бетерү турындагы карары

88. Түбәндә санап кителгәннәрнең кайсысы Көмеш гасыр мәдәнияте вәкиле булган?

1) М.И. Глинка, М.П. Мусоргский

2) И.П. Мартос, П.К. Клодт

3) К.С. Малевич, А.А. Блок

4) А.С. Грибоедов, Н.В. Гоголь

89. Түбәндә санап кителгәннәрнең кайсысы XVIII гасырның беренче яртысында чиркәүнең дәүләт идарәсе тармагына керүенә этәргеч ясаган?


1) патриархлык оешу

2) Изге Синод барлыкка килү

3) митрополитет кафедрасын Мәскәүдән Санкт-Петербургка күчерү

4) чиркәү җирләренә секулярлаштыру уздыру

90. Рәсемгә карагыз һәм сорауга җавап бирегез.



Рәсемдә нинди бәрелеш тасвирланган?

**1)** Синоп бәрелеше

**2)** Калиакрия янындагы бәрелеш

**3)** Цусим бәрелеше

**4)** Гренгам бәрелеше

91. XIX гасырда Россиянең үзенчәлекле, көнбатыштан аермалы булган үсеш юлын яклаучылар нинди исем алганнар?

**1)** социал-демократлар

**2)** славянофиллар

**3)** талымсызлар (нестяжатели)

**4)** декабристлар

92. Броненосец «Князь Потёмкин-Таврический» броненосецында матрослар восстаниесе ничәнче елда булган?

1) 1905 елда
2) 1907 елда
3) 1916 елда
4) 1917 елда

93. Түбәндә санап кителгән вакыйгаларның кайсысы 1905—1907 еллардагы Беренче Россия революциясе вакытында булган?

1) самодержавиене бәреп төшерү
2) Дәүләт думасы төзү
3) алпавыт җирләрен юкка чыгару
4) Бөтенроссия эшчеләр советлары һәм солдат депутатлары съезды эшли башлау

94. 1877–1878 елларда рус-төрек сугышы вакытында Шипка-Шейново янындагы бәрелештә дан казанган...

1) В.А. Корнилов
2) П.И. Багратион
3) М.Д. Скобелев
4) Ф.Ф. Ушаков

95. “Истәлекләр”дән өзекне укыгыз һәм авторын күрсәтегез.
“Император Александр III патшалык итүнең нигезендә акча реформасы алдан хәл ителгән иде. Мин бу реформаны үткәреп, рус финансларын коткардым, ныгыттым...”

**1)** Е.Ф. Канкрин

**2)** Н.Х. Бунге

**3)** И.А. Вышнеградский

**4)** С.Ю. Витте

96. Түбәндә санап кителгәннәрнең кайсысы рус мәдәниятенең Көмеш гасыр үзенчәлекләрен билгели?

**1)** рус театры барлыкка килү

**2)** рус классик музыкасының чәчәк атуы

**3)** архитектурада классик стильнең хакимлек итүе

**4)** сәнгатьтә һәм әдәбиятта яңа юнәлешләр эзләү

97. Халык җырыннан өзекне укыгыз һәм тасвирланган вакыйгаларның кайчан булуын күрсәтегез.
"19 февральдә крестьяннарны иреккә чыгардылар, ләкин халыкка җир бирмәделәр. Менә сезгә дворяннарның һәм патшаның шәфкате".

**1)** 1796 г.

**2)** 1803 г.

**3)** 1861 г.

**4)** 1883 г.

98. Тарихта 1839, 1897 елларны нинди вакыйга берләштерә?

**1)** Россия хакимияте тарафыннан финанслар реформасы үткәрелү

**2)** Кавказда зур сугыш хәрәкәтләре

**3)** Россия һәм Франция арасында халыкара килешүләр төзү

**4)** Уралда беренче  металлург заводлары төзү

99. Россия империясендә «Патша-азат итүче» дип исем бирелгән Александр Николаевич ничәнче елларда патшалык иткән?

1) 1796— 1801 елларда
2) 1801— 1825 елларда
3) 1825— 1855 елларда
4) 1855— 1881 елларда

100. 1840— 1850 елларда Россиянең үткәнен идеаллаштырган, аны әйдәп баручы Европа илләренә иярмичә, үз юлы белән барырга тиеш дип санаган иҗтмагый фикер вәкилләре ничек дип аталган?

1) нигилистлар
2) социалистлар
3) славянофиллар
4) староверлар

101. М.П. Мусоргский, Н.А. Римский-Корсаков кемнәр булганнар?

1) рәссамнар
2) композиторлар
3) архитекторлар
4) скульпторлар

102. Тарихи документтан өзек укыгыз һәм аның нинди вакыйга уңае белән язылганын билгеләгез.
“Думада катнашу өчен хәзер бернинди сайлау хокукына ия булмаган сыйныфларны җәлеп итәргә... Дәүләт думасы ризалыгыннан башка бернинди закон көчне кабул итә алмавын нык кагыйдә итеп урнаштырырга”.

**1)** Беренче Россия революциясе

**2)** Февраль революциясе

**3)** Генерал Л.Г. Корнилов чыгышы

**4)** Октябрь революциясе

103. Түбәндә санап кителгән шәхесләрнең кайсысы Бөек Екатерина патшалык иткән чорда халык чыгышлары белән җитәкчелек иткән?

**1)** Емельян Пугачёв һәм Салават Юлаев

**2)** Степан Разин һәм Василий Ус

223. 1905— 1907 елларда Россиядә революция барышында барлыкка килгән либераль лагерь ике сәяси партиядән тора: Конституцион демократлар партиясе һәм “17 октябрь союзы”. Бер иҗтимагый-сәяси агымга керүгә карамастан, бу партияләрнең программа эчтәлегендә аерымлыклар булган. Бу аерымлыкларны раслый торган кимендә ике фактны мисал итеп китерегез.

224. Александр II нең эчке сәясәтенең бер нәтиҗәсе булып нәрсә тора?

1) хәрби поселениеләрне бетерү

2) чиркәү биләмәләрен секулярлаштыру

3) дворяннарның өстенлеклрен законлаштыру

4) эчке таможня пошлиналарын бетерү

225. Ранглар турында табель кайчан барлыкка килә?

1) XVIII гасырның беренче чирегендә

2) XVIII гасырның икенче яртысында

3) XIX гасырның беренче яртысында

4) XIX гасырның икенче яртысында

226. Кайсы дәүләт органы Россиядә сарай борылышлары чоры вакыйгалары белән турыдан-туры бәйле?

1) Югары эш башкару комиссиясе

2) Яшерен эшләр боерыгы

3) Югары яшерен совет

4) Император канцеляриясенең III бүлеге

227. XIX гасыр ахырында С.Ю. Витте тарафыннан үткәрелгән финанс реформасы нәтиҗәсендә...

1) акча әйләнешеннән алтын тәңкәләр алына

2) Россия икътисадына чит ил капиталы керү арта

3) кәгазь ассигнацияләрне чыгару тулысынча туктатыла

4) халыкның матди хәле бик нык начарая

228. Түбәндә санап кителгән вакыйгаларның кайсысы иң ахырда булган?

1) Югары яшерен советны бетерү
2) Россияне империя дип игълан итү
3) Екатерина II нең Уложенный комиссияне чакыруы
4) дворяннарның ireклегe турында манифест чыгару

229. XVIII гасырның икенче яртысында рус-төрек сугышы вакытында Измаил крепостен алганда кайсы рус полководцы гаскәр белән җитәкчелек иткән?

1) Б.К. Миних
2) А.В. Суворов
3) П.И. Багратион
4) Б.П. Шереметев

230. Чернигов полкы восстаниесе белән кем җиткчелек иткән?

1) К.Ф. Рылеев
2) П.Г. Каховский
3) С.П. Трубецкой
4) С.И.  Муравьёв-Апостол

231. Беренче Россия революциясе вакытында самодержавиянең какшамаслыгы турында идеяне яклаган партияне күрсәтегез.

1) Социал-революционерлар партиясе
2) «17 октябрь союзы»
3) Конституцион-демократик партия
4) «Рус халкы союзы»

232. Барыннан да соңрак булган вакыйганы күрсәтегез.

1) Коткару союзы төзелү
2) Чернигов полкы восстаниесе
3) Көньяк җәмгыяте төзелү
4) Сенат мәйданында восстание

233. Түбәндә санап кителгәннәрнең кайсысы XVIII гасырда Россия империясенә Кырым ханлыгы территориясен кушуның нәтиҗәсе булып тора?

1) Осман империясенең таралуы
2) Осман империясе белән Россия арасында мөнәсәбәтләрнең кискенләшүе
3) Речь Поспалитаяның икенче һәм өченче бүлекләре
4) Россия һәм Болгария арасында дипломатик мөнәсәбәтләр урнашу

234. Шул заман кешесенең истәлекләреннән өзек укыгыз һәм рус армиясенең кайсы гаскәр башлыгы турында сүз баруын күрсәтегез.

“Аны гаскәр башлыгы итеп кую гаскәрдә һәм халыкта зур куаныч тудырды. <…> Петербург, Мәскәү, Россия аннан яңа дан-шөһрәт, яңа җиңүләр көтте. <…> Барлык сәламләүләргә тәҗрибәле полководец: “Ходай, Наполеонны җиңәргә түгел, алдарга мөмкинлек бир!”- дип җавап бирә иде.

1) М.Б. Барклай де Толли
2) М.И. Кутузов
3) П.И. Багратион
4) П.Х. Витгенштейн

235. Ничәнче елда Россиядә Дәүләт думасы төзелү турында император манифесты басылып чыккан?

1) 1810 елда

2) 1861 елда

3) 1905 елда

4) 1917 елда

236. Түбәндә санап кителгәннәрнең кайсысы Төньяк сугышы башлануның сәбәбе булып тора?

1) Россиянең Польшаны бүлүдә катнашырга омтылуы

2) Россиянең Балтыйк диңгезенә чыгу мөмкинлеген алу

3) Россиянең Ак диңгездә позицияләрен ныгытырга омтылуы

4) хәрби яктан ныгып килүче Төркиядән куркыныч янау

237. Император указыннан өзек укыгыз һәм шул императорны күрсәтегез.
«1. Лицей ачуның максаты – бигрәк тә Дәүләт хезмәте бүлекләре өчен кирәк булган яшьләргә белем бирү. <…>
3. Лицейда Дәүләт хезмәте бүлекләре өчен әһәмиятле һәм әдәпле, яхшы тәрбия алган яшьләр өчен кирәкле булган предметлар укытыла. <…>
14. Лицей хокуклары һәм өстенлекләре буенча Россия Университетлары белән тигез дәрәҗәдә тора».

1) Пётр III

2) Екатерина II

3) Павел I

4) Александр I

238. 1735—1739 елларда рус-төрек сугышы барышында Кырымга кергән рус армиясе белән кем җитәкчелек итә?

1) Б.Х. Миних

**2)** А.Д. Меншиков

**3)** П.А. Румянцев

**4)** А.В. Суворов

239. Барыннан да соңрак булган вакыйганы күрстегез.

**1)** «Земля и воля» оешмасы төзелү

**2)** Халык арасына керү

**3)** Александр II үтерелү

**4)** «Хезмәтне азат итү» төркемен төзелү

240. Нинди сугыш барышында рус армиясе Тарутин манёврын башкарган?

**1)** 1812 елгы Ватан сугышы

**2)** Җидееллык сугыш

**3)** 1808—1809 еллардагы рус-швед сугышы

**4)** Беренче бөтендөнья сугышы

241. Кайсы елда дворяннарга жалованный грамота кертелә?

**1)** 1722 елда

**2)** 1762 елда

**3)** 1785 елда

**4)** 1861 елда

242. Нинди вакыйга П.Д. Киселёв эшчәнлеге белән бәйле?

1) гомуми хәрби йөкләмә кертү
2) дәүләт авылы реформасы
3) акча әйләнеше нигезе булганрак көмеш акча кертү
4) Дәүләт думасы төзү

243. 1856 елда Париж солыхы төзүнең бер нәтиҗәсе булып нәрсә тора?

1) Россиянең Балканда йогынтысы арту
2) Кара диңгез регионында Россиянең йогынтысы кимү
3) Россиянең Севастополь шәһәрен югалтуы
4) Изге союз төзелү

244. Шул заман тарихчысының хезмәтеннән өзек укыгыз һәм кайсы дәүләт башлыгы турында сүз барганын күрсәтегез.

“[Бу дәүләт башлыгы] Россияне кайчан да булса барыбыр үтәчәк берничә үсеш этабы аркылы зур сикереш ясарга мәҗбүр итте... Кайвакыт аны тәхеттәге революционер, ә реформаларын - өстә ясалган революция дип атыйлар. Ләкин патшаның революционлыгы, гомумән алганда, парадоксаль булса да, консерватив характерда иде. Дәүләтне нигезенә самодержавияле-крепостнойлык принципларын салып модернизацияләү – төп максаты шул булды. Башкача әйткәндә, реформалар Россиягә капитализм юнәлешендә үсәргә ирек бирмичә, киресенчә, феодаль системаны ныгыталар иде!

1) Пётр I
2) Николай I
3) Александр II
4) Николай II

245. XVIII гасырның икенче яртысында күренекле рус флот башлыгы -

**1)** В.А. Корнилов

**2)** М.П. Лазарев

**3)** П.С. Нахимов

**4)** Ф.Ф. Ушаков

246. Ничәнче елда Россия империясендә Дәүләт советы оешкан?

**1)** 1797 елда

**2)** 1810 елда

**3)** 1826 елда

**4)** 1906 елда

247. Кайсы сугыш барышында Нарва янындагы бәрелеш булган?

**1)** Җидееллык сугыш

**2)** Төньяк сугышы

**3)** 1812 елгы Ватан  сугышы

**4)** 1877— 1878 еллардагы рус-төрек сугышы

248. Россиянең Кырым сугышында җиңелүенең бер нәтиҗәсе булып нәрсә тора?

**1)** ил җитәкчелегенең реформалар үткәрү кирәклегенә төшенүе

**2)** хәрби поселениеләр төзи башлау

**3)** Россиядә сәнәгать борылышы башлану

**4)** дәүләт төзелеше реформалары проектларын тормышка ашырудан баш тарту

249. Кырым Россия империясенә ничәнче елларда кушылган?

**1)** 1720 елларда

**2)** 1780 елларда

**3)** 1810 елларда

**4)** 1870 елларда

250. Манифесттан өзек укыгыз һәм шул Манифестны чыгарган монархны атагыз.
“Дәүләт эшләре белән идарә итү 8 бүлектә башкарыла, һәрберсен аерым Министрлык тәшкил итә һәм Министр тарафыннан идарә ителә. Министрны без хәзер яки киләчәктә билгеләп куя алабыз.
Бүлекләр түбәндәгечә:
1. Хәрби Коры җир, 2 Диңгез Көчләре, 3. Чит ил Эшләре, аның эшләре беренче Дәүләт Коллегияләрендә алып барыла, 4. Юстиция бүлеге, 5 Эчке Эшләр, 6. Финанслар, 7. Коммерция һәм 8. Халык мәгарифе”.

**1)** Пётр I

**2)** Александр I

**3)** Николай I

**4)** Александр III

251. Б.Н. Чичерин истәлекләреннән өзек укыгыз һәм тасвирланган вакыйгаларның кайсы вакыт аралыгында булганын күрсәтегез.
“Ике ай буе Россия ниндидер сәер уңайсызлану һәм аптырау халәтендә калды; беркемнең дә кулы эшкә ятмады, акыл һәм хисләр катып калган кебек булды. Үлгән патшаны азат ителгән крестьяннар да, элеккеге сарай кешеләре дә яраттылар; җәмгыятьтә аны шәхсән белгән һәм рәхимлеге, игелекле эш эшләргә әзер торуы турында ишеткән барлык кешеләр аңа җанын фида кылдылар һәм тугрылыклы булдылар”.

**1)** 1820 еллар уртасы

**2)** 1850 еллар уртасы

**3)** 1880 еллар башы

**4)** 1890 елларның беренче яртысы

252. Халык арасына керү ничәнче уньеллыкта булган?

**1)** 1820 елларда

**2)** 1840 елларда

**3)** 1870 елларда

**4)** 1890 елларда

253. Анна Иоанновнага юнәлдерелгән кондицияләр күздә тоталар

**1)** Россия дәүләтендә абсолютизмны раслауны

**2)** дворяннарның өстенлекләрен чикләүне

**3)** сайлап куелган власть органнарын кертүне

**4)** император властен чикләүне

254. 1848–1849 еллардагы Европа революциясенең император Николай I нең эчке сәясәтенә йогынтысы нәрсәдә күренде?

**1)** Россия империясендә суд системасын либеральләштерүдә

**2)** цензура изүенең көчәюендә

**3)** Финляндия һәм Польшага конституцияләр бирүдә

**4)** фабрика законын төзүдә

255. Төньяк сугышының хәлиткеч бәрелешләре кайчан булган?

**1)** XVI гасырның икенче яртысында

**2)** XVII гасырның икенче чирегендә

**3)** XVIII гасырның беренче чирегендә

**4)** XIX гасырның беренче яртысында

256. Түбәндә санап кителгәннәрнең кайсысы Бөек илчелек эшчәнлегенең бер нәтиҗәсе булып тора?

**1)** Кара диңгезгә чыгу өчен көрәш кискенләшү

**2)** Төньяк союзы төзелү

**3)** Англиягә каршы коалиция төзү

**4)** протекционизм сәясәтеннән баш тарту

257. Ничәнче елда Россиядә Дәүләт думасы төзелү турында император манифесты басылып чыга?

**1)** 1825 елда

**2)** 1881 елда

**3)** 1905 елда

**4)** 1907 елда

258. Кем җитәкчелегендә рус эскадрасының җиңүен белгәч, А.В.Суворов: “Ник Корфу янында мин мичман булса да булмадым икән!” – дип кычкырган?

**1)** В.А. Корнилов

**2)** П.С. Нахимов

**3)** Ф.Ф. Ушаков

**4)** Ф.М. Апраксин

259. Россиянең XIX гасыр тышкы сәясәтендә “Көнчыгыш мәсьәләсе” төшенчәсе нәрсә аңлаткан?

**1)** Урта Азиядә йогынты сфераларын бүлүгә бәйле Англия белән конфликт

**2)** Япониянең Куриль утраулары буенча Россиягә территориаль дәгъвасы

**3)** Амур буеның бәхәсле территорияләренә бәйле Россия һәм Кытай конфликты

**4)** Осман империясе хакимлегендәге территорияләргә бәйле Европа илләре арасында туган каршылыклар

260. Е.И. Пугачёв җиткчелегендәге восстаниенең бер нәтиҗәсе булып нәрсә тора?

**1)** Уложенный комиссия эшчәнлеге тәмамлану

**2)** губерна реформасы үткәрү

**3)** качак крестьяннарны вакыт ягыннан чикләүсез эзәрлекләүне кертү

**4)** чиркәү җирләрен секулярлаштыру

261. Тарихи документтан өзек укыгыз һәм аның язылу елын күрсәтегез.
“Ст. 2. Суд власте... барлык катлам кешеләргә, һәм гражданнар, һәм җинаять эшләренә карый.
Ст. 3. Мировой судья – бер генә кеше башкара торган власть, мировой судьялар съездлары, округ судлары, суд палаталары һәм Сенат - коллегиальлек урнаштыруның нигезе”.

**1)** 1803 ел

**2)** 1832 ел

**3)** 1864 ел

**4)** 1887 ел

262. Илне модернизацияләү процессында дәүләтнең актив ролен яклап чыга

**1)** В.К. Плеве

**2)** К.П. Победоносцев

**3)** С.Ю. Витте

**4)** Д.А. Толстой

263. Нева елгасы ярларында Санкт-Петербург шәһәренә кайчан нигез салына?

**1)** 1703 елда

**2)** 1709 елда

**3)** 1712 елда

**4)** 1721 елда

264. 1870-1880 елларда Россия белән Англия арасында мөнәсәбәтләрнең кискенләшүе Россиягә нинди территорияне кушу белән бәйле?

**1)** Урта Азияне

**2)** Кырым ярымутравын

**3)** Польшаны

**4)** Финляндияне

265. Тарихи чыганактан өзек укыгыз һәм анда тасвирланган теориянең исемен күрсәтегез.
“Россия көчле, кешеләргә рәхимле, мәгърифтле самодержавие рухы белән яши һәм саклана дигән тирән шаныч халык аңына үтеп керергә һәм аның белән бергә үсеш алырга тиеш. Ике милли башлангыч - православие һәм самодержавие белән өченчесе дә, шундый ук әһәмиятлесе, шундый ук көчлесе бар – ул халыкчанлык”.

**1)** мәгърифәтле абсолютизм теориясе

2) рәсми халыкчанлык теориясе
3) крестьян социализмы теориясе
4) Россия һәм Европаның бергә үсеше теориясе

266. “Ул пәрәмәч сатучыдан рус армиясенең генералиссимусы дәрәҗәсенә кадәр барып җитте. Петр I киткән вакытларда ул ил белән идарә итте. Екатерина I не тәхеткә күтәреп, Россиянең чын идарәчесенә әйләнде”. Кайсы дәүләт эшлеклесе турында сүз бара?

1) И.И. Шувалов
2) А.Д. Меншиков
3) Г.А. Потёмкин
4) А.И. Остерман

267. XIX гасырның беренче чирегенә кемнәрнең эшчәнлеге туры килә?

1) декабристларның
2) славянофилларның
3) петрашевчыларның
4) народникларның

268. Россиянең Босфор һәм Дарданеллы бугазын контрольгә алу омтылышы нәрсә белән бәйле?

1) Тальзит солыхына кул кую
2) Кырым сугышы башлану
3) “Өч император союзы” төзелү
4) Венгриягә 150 меңлек Россия корпусын җибәрү

269. Кем үзен могҗизалы рәвештә коткарылган Петр III дип игълан итә?

1) И.И. Болотников
2) С.Т. Разин
3) К.А. Булганвин
4) Е.И. Пугачёв

270. Ничәнче елда дворяннарга жалованный грамота бастырыла?

1) 1714 елда
2) 1731 елда
3) 1762 елда
4) 1785 елда

271. Түбәндә санап кителгән сугышларның кайсысы Ништадт солыхына кул кую белән тәмамлана?

1) Җидееллык сугышы
2) Төньяк сугышы
3) Ватан сугышы
4) Кырым сугышы

272. Александр II хакимлек итүнең бер нәтиҗәсе булып тора

1) Россиядә тимер юллар төзелә башлау
2) Дәүләт думасы төзелү
3) крепостной хокукны бетерү
4) Россиягә Финляндияне кушу

273. Полтава сугышы кайчан булган?

1) 1700 елда
2) 1709 елда
3) 1714 елда
4) 1720 елда

274. Түбәндә санап кителгән үзгәрешләрнең кайсысы Беренче Россия революциясе вакытында үткәрелә?

1) Советлар власте урнаштыру
2) Россияне республика дип белдерү
3) Дәүләт думасы төзелү
4) Учредительное собрание җыю

275. Түбәндә санап кителгәннәрнең кайсысы XIX гасырның беренче яртысында товар-акча мөнәсәбәтләре үсеше нәтиҗәсе булып тора?

1) крепостной бәйлелекне бетерү
2) авыл общинасын ныгыту
3) крестьянлыкның катламлануы
4) авылда натураль хуҗалык үсеше

276. Хәзерге заман тарихчысының хезмәтеннән өзек укыгыз һәм беренче җөмләдә нинди вакыйга турында сүз баруын әйтегез.
“Бу вакыйга Петр I гә аның тарафыннан төзелгән коры җир һәм диңгез көчләре белән тарихи яктан әһәмиятле эшләр башкарырга мөмкинлекне, ләкин шулар ук иске тип гаскәрләрнең чагыштырмача артталыгын һәм ышанычсызлыгын, чит ил үрнәгендә төзелгән гаскәрләрнең җитешмәвен күрсәттеләр. Хәрби һәм башка эшләрдә көнбатыш күршеләреннән калышмас өчен 25 яшьлек Пётр I тәүге

тапкыр чит илгә бара. В. Ключевский сүзләре буенча, Пётр I, көнбатыш Европага эләккәч, аның цивилизация остаханәсенә йөгереп керә һәм аннан беркая да китәсе килми”.

1) Икенче Азов походы
2) Кырым походы
3) Прут походы
4) Каспий походы

277. Малоярославец янында бәрелеш кайсы сугыш вакытында булган?

1) Кырым сугышы
2) Төньяк сугышы
3) 1812 елгы Ватан сугышы
4) Беренче бөтендөнья сугышы

278. XVIII гасырда сарай переворотлары эпохасы башлануга нәрсә этәргеч ясый?

1) Э. Биронның сарайда йогынтысы арту
2) Петр I нең тәхет варислыгы турында указы
3) Петр I нең губерна реформасы
4) «Верховниклар» тарафыннан Анна Иоанновнаның хакимлеген чикләргә тырышу

279. Тарихчы язмасыннан өзек укыгыз һәм кайсы императрица турында сүз баруын билгеләгез.
“Императрицаның халыкның хәлен җиңеләйтү юлларын эзләве аның тарафыннан тупланган “Уложение турында комиссия” ("Комиссия об уложении") дигән хезмәте раслый. Бу хезмәт аны язуда Григорий Александрович Потёмкин актив катнашкан

булуы белән дә кызыклы... Инде ул шул  вакытта ук кече халыкларның холкын, тарихын, көнкүрешен, гадәтләрен  тәсфилләп өйрәнә һәм бу аңа Новороссия һәм Россиянең башка көньяк губернияләре белән идарә итү чорындагы эшчәнлегенә бик ярдәм итә. Әлеге чорда Григорий Александровичның крестьяннарны азат итү турында язмалар һәм Россия тарихы турында хезмәтләр  авторы Елагин белән якынаюы билгеле. Потёмкин Россиядә крепостной правоны бетерү яклы булган, императрица да бу мәсьләне кузгата. Ләкин Россия бу чорда андый адымга әзер булмый әле”.

**1)** Екатерина I

**2)** Анна Иоанновна

**3)** Елизавета Петровна

**4)** Екатерина II

280. “Өч император союзы”н төзү турындагы документка кем кул куя?

**1)** Александр I

**2)** Николай I

**3)** Александр II

**4)** Александр III

281. Россия кайчан империя дип игълан ителә?

**1)** 1613 елда

**2)** 1700 елда

**3)** 1721 елда

**4)** 1762 елда

282. Синоп диңгез бәрелеше кайсы сугыш вакытында булган?

1) Төньяк сугышы
2) 1787— 1791 еллардагы рус-төрек сугышы
3) 1812 елгы Ватан сугышы
4) Кырым сугышы

283. Екатерина II үткәргән эчке сәясәтнең бер нәтиҗәсе булып нәрсә торган?

1) эчке таможня пошлинасын бетерү
2) крестьяннарны крепостной бәйлелектән азат итү
3) дворяннарның өстенлекләрен законлаштыру
4) яңа законнар язу

284. Император көндәлегеннән өзек укыгыз һәм нинди вакыйга турында сүз баруын ачыклагыз.
“Авыр көн! Эшчеләрнең Кышкы сарайга барып җитү теләге җитди тәртипсезлекләр китереп чыгарды. Гаскәрләр шәһәрнең төрле урыннарыннан атарга тиеш булдылар, үлгән һәм яраланган кешеләр күп иде. Йә, алла, ничек кызганыч һәм авыр!”.

1) декабристлар восстаниесе
2) Ходын кырындагы трагедия
3) Канлы якшәмбе
4) Лена атышы

285. Александр I нең замандашын күрстегез.

1) М.Д. Скобелев
2) П.И. Шувалов

**3)** С.Ю. Витте

**4)** П.И. Пестель

286. Түбәндә санап кителгән мәдәният эшлеклеләренең кайсысы рәссам-передвижник булган?

**1)** К.П. Брюллов

**2)** В.Г. Перов

**3)** А.А. Иванов

**4)** М.Ф. Казаков

287. XVIII—XIX гасырларда Россия империясендәге югары административ-территориаль бүленешләр ничек дип аталган?

**1)** губернияләр

**2)** волостьлар

**3)** станицалар

**4)** уделлар

288. XIX гасырда хәрби  поселенияләр дип аталган

**1)** чик янындагы хәрби лагерьлар

**2)** гаскәрләрне басып алынган территорияләрдә урнаштыру

**3)** казак гаскәрләреурнашкан районнар

**4)** солдатларның хәрби хезмәт белән хуҗалык эшен берләштергән гаскәр оешмалары

289. XIX гасырның беренче чирегендә хәрби поселениеләр төзүнең сәбәбе булып торган...

1) армиягә рекрут җыюлары бетү
2) авыл кешеләренең ризасызлыгы һәм массакүләм протестлар
3) хәрби поселенецлар хисабына хакимиятнең социаль терәге киңәюе
4) казак гаскәрләрен таркату

290. Тильзит солыхы шартларын үтәп, Россия тиеш булган...

1) Франция хисабына контрибуция түләргә
2) Англиягә сугыш игълан итәргә
3) Финляндиядән баш тартырга
4) Континенталь блокадага кушылырга

291. Кайсы рәттә Россия белән Франция сугышкан еллар күрсәтелгән?

1) 1812 ел, 1853- 1856 еллар
2) 1803 ел, 1806-1812 еллар
3) 1825 ел, 1833-1837 еллар
4) 1881 ел, 1892-1893 еллар

292. Түбәндә санап кителгәннәрнең кайсысы Төньяк сугышы башлануның сәбәбе булып тора?

1) Россиянең Германиянең кушылуына каршы килергә тырышуы
2) Россиянең Балтыйк диңгезенә чыгу зарурлыгы
3) Россиянең Франция һәм Англия белән мөнәсәбәтләре кискенләшүе
4) Петр I тарафыннан Софья патшабикәнең хакимияттән төшерелүе

293. Император канцеляриясенең III бүлеге кем хакимлегендә төзелә?

1) Павел I
2) Александр I
3) Николай I
4) Николай II

294. Түбәндә санап кителгәннәрнең кайсысы А.А. Аракчеев эшчәнлеге белән бәйле?

1) бөтен катламнар өчен хәрби йөкләмә кертү
2) бурычлы крестьяннар турында указ чыгару
3) хәрби поселениеләр төзү
4) «Чуен уставы» кабул итү

295. Халык мәгарифе министры докладыннан өзек укыгыз һәм кайсы императорга тәкъдим ителгәнен күрсәтегез.

“... уку җитәкчелегенә гимназиягә һәм прогимназиягә бай кешеләрнең, ягъни өйдә тиешле тәрбия бирә алулары турында ышандыра алган һәм игътибарлы, уку өчен тиешле шартлар тудыра алган кешеләрнең балаларын гына кертергә. Шушы кагыйдәне өзлексез үтәгән вакытта гимназия һәм прогимназия кучер, лакей, пешекче, кер юучы, вак кибетче һәм шундый кешеләрнең балаларыннан бушап калачак. Искәрмә булганрак, сәләтле, гадәттән тыш осталыклары булган балаларны гына алырга, ләкин үз мохитләрендә тотарга”.

1) Николай I
2) Александр II
3) Александр III
4) Николай II

296. Түбәндәге XVIII гасырның беренче чирегендә кабул ителгән документларның кайсысы дәүләт һәм хәрби хезмәт үтү тәртибенең регламентын билгеләгән?

**1)** рангалар турында табель

**2)** дворяннарга жалованный грамота

**3)** дворяннарның ирeклеге турында манифест

**4)** бер варислык турында указ

297. XVIII гасырның беренче чирегендә нинди дәүләт органы барлыкка килгән?

**1)** Хакимлек итүче сенат

**2)** Министрлар кабинеты

**3)** Яшерен эшләр приказы

**4)** Учредительная комиссия

298. Ничәнче елда Россия империя дип игълан ителә?

**1)** 1682 елда

**2)** 1709 елда

**3)** 1721 елда

**4)** 1725 елда

299. Петр I вакытында нинди югары дәүләт органы оеша?

**1)** Дәүләт советы

**2)** Хакимлек итүче сенат

**3)** Министрлар кабинеты

**4)** Югары яшерен совет

300. Россиядә соңгы сарай перевороты кайчан булган?

1) 1801 елда
2) 1853 елда
3) 1881 елда
4) 1894 елда

301. Александр I катнашында нинди тышкы сәяси союз төзелгән?

1) Изге союз
2) Өч император союзы
3) Антанта
4) Өчлек союзы

302. Түбәндә санап кителгән вакыйгаларның кайсысы XIX гасырның беренче яртысында булган?

1) крепостное правоны бетерү
2) Крестьяннарның җир салымы банкы оешу
3) Дәүләт милеге министерствосы барлыкка килү
4) армиягә рекрут җыюлары кертү

303. 1802 елда нинди вакыйга булган?

1) Уложенный комиссияне чакырып алу
2) Дәүләт думасы оешу
3) Мәскәү университеты ачылу
4) министерстволар төзелү

304. “Армия яңалыклары” («Известия об армии») журналыннан өзек укыгыз һәм анда тасвирланган вакыйгаларның ничәнче елда булуын әйтегез.

“Армия атнадан артык Тарутин авылы янында, Нара елгасының уң як ярында тора һәм, тынычлык хәлатендә яңа көч җыя. Полклар инфантерия генералы кенәз Лобанов-Ростовский тарафыннан формалаштырылган Ростов гаскәрләре белән тулыландырыла. Лагерьда французлар белән сугышырга ашкынып торучы рекрутны өйрәтүләр уздырыла... Армия ял итә һәм өстәмә көч җыя”.

**1)** 1805 елда

**2)** 1812 елда

**3)** 1826 елда

**4)** 1853 елда

305. Түбәндә санап кителгән вакыйгаларның кайсысы 1815 елда булган?

**1)** Бородино сугышы

**2)** Изге союз төзелү

**3)** рус армиясенең Чит ил походы башлану

**4)** Россия һәм Франция арасында Тильзит солыхына кул кую

306. Түбәндә санап кителгән вакыйгаларның кайсысы иң алдан булган?

**1)** декабристлар восстаниесе

**2)** Шипка оборонасы

**3)** Польшада восстание

**4)** Венгерия революциясен басу

307. Ничәнче елда крепостной хокук бетерелә?

**1)** 1859 елда

2) 1861 елда

3) 1874 елда

4) 1881 елда

308. Түбәндә санап кителгән гаскәр башлыкларының кайсысы 1812 елгы Ватан сугышында дан казанган?

1) П.И. Багратион

2) И.В. Гурко

3) П.С. Нахимов

4) М.Д. Скобелев

309. Декабристлар ничәнче елда Сенат мәйданында восстание оештырганнар?

1) 1816 елда

2) 1818 елда

3) 1825 елда

4) 1826 елда

310. 1830— 1831, 1863— 1864 еллар Россия тарихында нәрсә белән бәйле?

1) сайлап куелган власть органнары эшчәнлеге

2) финанс реформалары үткәрү

3) Польшада милли-азатлык восстаниеләре

4) славянофилларның әдәби журналлар бастырып чыгаруы

311. Түбәндә санап кителгәннәрдән кайсысы XIX гасырның беренче яртысында Россиянең икътисади үсешенең үзенчәлеген билгеле?

1) беренче мануфактуралар барлыкка килү
2) Бөтенроссия базары төзелә башлау
3) сәнәгать переворотлары башлану
4) сәнәгатьне национализацияләү

312. XVIII—XIX гасырларда сезонлы эшләргә шәһәргә китүче һәм тапкан акчаларының бер өлешен алпавытка алып кайтып бирүче крестьяннар категориясе ничек дип аталган?

1) ирекле игенчеләр
2) сукадан салым түләүчеләр
3) отходниклар
4) вакытлыча бурычлылар

313. Түбәндә санап кителгән документларның кайсысы дворяннарны мәҗбүри хәрби һәм гражданнар хезмәтеннән азат иткән?

1) эшмәкәрлек ирекe турында указ
2) Ранглар турында табель
3) бер варислык турында указ
4) дворяннар ирекe турында манифест

314. Николай I кушуы буенча Россия законнарын кодификацияләү эше белән җитәкчелек иткән дәүләт эшлеклесен күрсәтегез.

1) А.А. Аракчеев
2) М.М. Сперанский
3) П.Д. Киселёв
4) Е.Ф. Канкрин

315. Түбәндә санап кителгән төшенчәләрнең кайсысы 1874 елда хәрби реформалар үткәрү белән бәйле?

1) «яңа строй» полклары
2) рекрут җыюлары
3) бөтен катламнар өчен хәрби йөкләмә
4) регуляр армия

316. Түбәндә санап кителгән дәүләт органнарының кайсысы алданрак төзелгән?

1) Югары эш йөртү комиссиясе
2) Хакимлек итүче сенат
3) Югары яшерен совет
4) Дәүләт советы

317. Түбәндә санап кителгән  идеяләрнең кайсысын славянофиллар яклаган?

1) крепостной хокукны саклау
2) крестьян общинасын ликвидацияләү
3) Земский соборны  чакыру
4) самодержавиене бетерү

318. Россия империясенең Кырым сугышында катнашуының бер нәтиҗәсе булып нәрсә торган?

1) Балтыйк буен кушу
2) Кара диңгездә хәрби флот тотуны тыю
3) Балканда йогынтының ныгуы
4) Россия империясенә Кырымны кушу

319. Тарихчы язмасыннан өзек укыгыз һәм кайсы патшабикә турында сүз баруын күрсәтегез.

“Мәскәүгә 500дән күбрәк депутат җыелды. Уложение комиссиясендә иң күбе шәһәр вәкилләре, икенче урында дворяннар иде. <…>

Патшабикә депутатлар өчен үз кулы белән "Наказ" язды.

Бу документта ул француз мәгърифәтчеләрен юкка гына өйрәнмәвен күрсәтте.

Игелек һәм намуслык төшенчәләре “Наказ”да беренче планга чыгарылган һәм, патшабикә фикеренчә, депутатлар яңа законнар эшләнгәндә шулар буенча эш итәргә тиешләр”.

1) Екатерина I
2) Анна Иоанновна
3) Елизавета Петровна
4) Екатерина II

320. Петр I вакытында төзелгән коллегияләрнең министерстволар белән алмашыну вакыт аралыгын күрсәтегез.

1) XVIII гасыр уртасы
2) XVIII гасыр ахыры
3) XIX гасыр башы
4) XIX гасыр уртасы

321. Түбәндә санап кителгән вакыйгаларның кайсысы XVIII гасырда булган?

1) Россияне империя дип игълан итү
2) Дәүләт советы оешу
3) местничество бетерелү
4) Собор уложениесен кабул итү

322. Петр I патшалык итү чорында нинди идарә итү органнары барлыкка килгән?

**1)** приказлар

**2)** коллегияләр

**3)** министерстволар

**4)** земстволар

323. Түбәндә санап кителгән вакыйгаларның кайсысы 1861 елның 19 февралендә булган?

**1)** Александр II гә һөҗүм итү

**2)** крестьяннарны азат итү турында манифестка кул кую

**3)** I Дәүләт думасы ачылу

**4)** самодержавиенең какшамаслыгы турында манифест чыгару

324. Түбәндә санап кителгәннәрнең кайсылары 1825 елның 14 декабрендә Сенат мәйданы вакыйгаларында катнашканнар?

**1)** Н.И. Панин, А.Н. Радищев

**2)** М.А. Милорадович, П.Г. Каховский

**3)** М.Д. Скобелев, А.И. Желябов

**4)** А.П. Ермолов, Д.В. Давыдов

325. 1861 елгы Крестьян реформасы нәтиҗәсендә

**1)** крестьяннарга җир белән общинадан чыгарга рөхсәт ителә

**2)** крестьяннар шәхси ирек алалар

**3)** крестьян кооперативлары барлыкка килә

**4)** алпавыт җирбиләүчелеге бетерелә

326. Түбәндә санап кителгәннәрдән кайсысы 1861 елгы Крестьян реформасы нәтиҗәсенә туры килә?

1) дәүләт крестьяннары дигән категория барлыкка килү
2) крепостной хокук бетерелү
3) җан башыннан түләү кертелү
4) алпавыт җирбиләүчелеге бетерелү

327. Д.А. Милютин кайсы манифестны язуда катнашкан?

1) Дәүләт советын оештыру турында
2) йолым түләүләрен бетерү турында
3) вакытлыча бурычлы крестьяннарны мәҗбүри йолымга күчерү турында
4) гомуми хәрби йөкләмә кертү турында

328. Түбәндә санап кителгәннәрдән кайсысы XX гасыр башында Россиянең икътисади үсешенә туры килә?

1) икътисадның күпьяклы үсеше
2) икътисадка чит ил капиталын җәлеп итүдән баш тарту
3) дәүләтнең ил икътисадына катнашмавы
4) сәнәгать җитештерүенең түбән темплар белән үсүе

329. Яшь дворянин патша кушуы буенча казна акчасына Голландиягә корабль эшенә өйрәнергә җибәрелә. Укып бетергәннән соң ул Россиягә кире әйләнеп кайта, Балтыйк буенда Россия флоты төзелешендә һәм үсешендә актив роль уйный, Швеция белән диңгез сугышы вакытында үзен яхшы яктан белдертә.

1. Әлеге вакыйгалар кайсы патша идарә иткән вакытта булган?

2. Яшь дворянинны Голландиягә укырга җибәрү ихтияҗы ни сәбәпле барлыкка килгән?

3. Әлеге яшь дворянин Швеция белән нинди сугыш вакытында үзен яхшы яктан белдерткән?

330. Кышкы көндә 30 офицер-фикердәш Мәскәү һәм Гренадер полклары солдатларын һәм Гвардия диңгез экипажы матросларын Сенат мәйданына чыгардалар. Восстаниене оештыручылар яңа императорның тәхеткә менүен булдырмый калдырырга тырыштылар, шулай ук самодержавиене һәм крепостной хокукны бетерү омтылышы турында белдерделәр. Восстание бастырылды.

1. Бу тасвирланган вакыйга ничәнче елда һәм кайсы айда булган?
2. Кайсы император турында сүз бара?

Ни өчен восстание җиңелү белән тәмамланган? Бер сәбәбен күрсәтегез.

331. Түбәндә терминнар исемлеге бирелгән. Берсеннән кала, аларның барысы да сословиеләрне аңлата.

1) *купецлар;* 2) *пролетарийлар;* 3) *мещаннар;* 4) *казаклар;* 5) *дворяннар*.

Әлеге рәттән «төшереп калдырылырга» тиешле терминның тәртип номерын табыгыз һәм языгыз.

332. Түбәндә терминнар исемлеге бирелгән. Берсеннән кала, аларның барысы да иҗтимагый хәрәкәт вәкилләрен белдерә.

1) *народниклар;* 2) *отходниклар;* 3) *көнбатышчылар;* 4) *славянофиллар;* 5) *декабристлар*.

Әлеге рәттән «төшереп калдырылырга» тиешле терминның тәртип номерын табыгыз һәм языгыз.

333. Түбәндә терминнар исемлеге бирелгән. Берсеннән кала, аларның барысы да Александр I идарә итү чоры белән бәйле.

1) *министерстволар*; 2) *Дәүләт советы*; 3) *хәрби поселениеләр*; 4) *университет автономиясе*; 5) *сәнәгать перевороты*.

Әлеге рәттән «төшереп калдырылырга» тиешле терминның тәртип номерын табыгыз һәм языгыз

334. Түбәндә терминнар исемлеге бирелгән. Берсеннән кала, аларның барысы да XIX гасырның икенче яртысында Россия империясендәге иҗтимагый хәрәкәтне характерлый.
1) *террор*; 2*) халык арасына чыгу*; 3) *разночинецлар*; 4) *марксистлар*; 5) *«сул коммунистлар»*.
Әлеге рәттән «төшереп калдырылырга» тиешле терминның тәртип номерын табыгыз һәм языгыз.

335. ***Тарихчы язмаларыннан***
“Патшабикә, берсүзсез, крепостнойлыкка каршы булды, ләкин – күңелендә генә. Һичшиксез, крепостной хокук күренешләре коточкыч иде. Ләкин крепостнойлыкны бу вакытта җимерү ил өчен дә, патшабикәнең үзе өчен дә куркыныч тудыра иде. Пугачевчыларның котырынуы ачык күрсәтте: халык массалары азатлык төшенчәсен тигезлек, тәртип һәм җаваплылык белән бәйләмиләр, ә канлы анархия һәм явызларча кылану, яклаучысыз карт-корыларны, хатын-кызларны һәм сабыйларны мәсхәрә итү, гыйбадәтханәләрне, авылларны һәм шәһәрләрне җимерү, юлларда талау дип күз алдына китерәләр. Крепостной хокук, үзенең алпавыт – “ата”, крепостнойлар - аның “балалары” кебек мөнәсәбәтләр системасы белән кара халыкның кыргый асылын тыеп тора торган көч иде. Ул икътисадның таянычы, дворяннарның мул тормыш чыганагы булды; Сумарокавның: “Крестьяннар азат ителгән очракта дворяннар хезмәтчеләрне кайдан алырлар соң?”- дигән беркатлы соравы ул вакытта гади, эчкерсез сорау булып яңгырамады, алпавытларның оброк һәм барщина турында хафаланулары да урынлы иде.
Шуңа күрә бөтен өмет үзгәрешләрне эволюцияле юл белән генә гамәлгә ашыруда: законнарны камилләштерү, төгәл регламентлар кую, гомуми холыкларның йомшаруы, крестьяннар һәм еш кына крепостнойлары белән зур юлга баш күтәрергә чыгучы дворяннар арасында мәгърифәт тарату аркылы мөмкин булып күренә иде”.

Өзекнең беренче абзацыннан сәбәпләре икенче абзацта күрсәтелгән вәзгыять тасвирланган җөмләне табыгыз һәм языгыз. Әлеге хәлнең ким дигәндә ике сәбәбен күчереп языгыз.

Бу өзектә кайсы патшабикә турында сүз бара. Өзектә искә алынган халык чыгышы ничәнче елларда булган?

***Тарихчы язмаларыннан***

«Бу вакытка Польша-Литва корольлеге эчке сәбәпләр аркасында күзгә күренеп үз көчен югалта башлый, шуңа күрә Мәскәү дәүләтенә бөтен көчен көнбатышта Швеция белән көрәшүгә юнәлдерергә мөмкинлек туа. Ләкин бу көрәш зур, чиксез көч сарыф итүне таләп итә һәм ике дистә ел дәвам итә, Төркия белән көрәшү сәбәпле тагын да катлаулана. Ниһаять, патшаның үз алдына куелган, дөресрәге, йөз ел буе мирас булып күчеп бара торган бурычны үтәргә мөмкинлеге барлыкка килә. Патшаның хакимлек итү чорын өйрәнүченең дөрес фикеренчә, уңыш яуланса да, ул илнең фәкыйрьләнүе хисабына булган. Иң мөһиме, Иван III тарафыннан Мәскәү дәүләтенә кушылган, анан соң Иван IV тарафыннан кире бирелгән Ингрия, Карелия һәм Эстляндия Лифляндия белән бергә Россиягә яңадан кушылалар, ә бу аңа Балтыйк диңгезенә чыгарга мөмкинлек бирә.

Нева елгасы буенда булганчак башкала төзелә. Иван III вакытында көнбатыш илләренә бераз гына таныш булган Россия Европа державасы рангына күтәрелә, ә эллеккеге көндәше Польша нәкъ шушы вакытта икенчел держава дәрәҗәсенә төшә, күршеләре йогытысында яши, эчке фетнәләрдән иза чигә”.

Өзекнең беренче абзацыннан сәбәпләре икенче абзацта күрсәтелгән вазгыять тасвирланган җөмләне табыгыз һәм языгыз. Әлеге хәлнең ким дигәндә ике сәбәбен күчереп языгыз.

Текстта кайсы патша турында сүз бара? Текстта тасвирланган вакыйгаларның вакытын чирек гасыр төгәллегендә күрсәтегез.

336. 1830—1850 елларда Россиядә төрле иҗтимагый-сәяси агымнар барлыкка килә. Аларның игътибар үзәгендә иҗтимагый тормыш белән бәйле мәсьәләләр, ә төп мәсьәлә - илнең киләчәк үсеше юнәлешләре турында булган.

Россиядә славянофилларның кимендә ике вәкилен атагыз.

Славянофиллар нинди идеяләрне алга сөргәннәр? Кимендә өч положениене атагыз.

337. 1855 елда Александр II тәхеткә менә, ул тарихка “Азат итүче” исеме белән керә. Илдәге хәл анда мөһим үзгәртеп корулар уздыру зарурлыгын тудыра. Төп проблема крестьяннар белән бәйле булган.

Александр II хакимлек итү вакытында үткәрелгән крестьяннар реформасыннан тыш кимендә өч реформага мисал китерегез.

338. XVIII гасырның беренче яртысы мәдәният һәм фән өлкәсендә әһәмиятле үзгәртеп корулар белән билгеле.

Үткәрелгән үзгәртеп коруларның кимендә өч нәтиҗәсен атагыз.

Шул вакытның кимендә ике мәдәният һәм фән эшлеклесен атагыз.

339. XX гасыр башында Россия тарихында беренче революция кабына. Ул Россия җәмгыятендә элегрәк барлыкка килгән тирән каршылыклар һәм шуларның гасыр башында кискенләшүе нәтиҗәсендә булган.

Беренче Россия революциясенең кимендә өч сәбәбен атагыз.

340. Россия дәүләте тарихында 1812 елгы Ватан сугышы илнең халыкара йогынтысын арттырган һәм озак вакытка Европа сәясәтендә алдынгы рольдә торырыга мөмкинлек биргән күренекле вакыйга.

1812 елгы Ватан сугышы башлануның кимендә ике сәбәбен атагыз.